**КАРАР**

**“05” апрель 2024 ел № 1**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Якты-Көн авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Якты-Көн авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Якты-Көн авылында 2024 елның 05 апрелендә “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Якты-Көн авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 нче ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Якты-Көн авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чилтәрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү,төзеклэндерү, карап тоту (Якты-Көн авылы, Якты урамы юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларын вак таш белән тигезләү)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 57 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 30 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 30 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегендә

халык  җыены узды, җыены нәтиҗәләредәрес дөрес дип таныырга.

2. «Сез 2024 елда  яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы  Кәче авыл җирлеге Якты-Көн авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган  кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны  һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын,  хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-- торак пункт  челтәрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү,төзекләндерү, карап тоту ( Якты-Көн авылы, Якты урамы юл-урам  челтәрендәге автомобиль  юлларын вак таш белән   тигезләү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда,  авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне  хәл итүгә тотарга» соравы буенча карар кабул ителде дип таныырга».

3. Әлеге карарны гражданнар  күп җыела торган урыннарда: ТР, Арча районы, Якты Көн авылы, Якты урам, 30а йорты адресы буенча мәгълүмат стендында,  Арча муниципаль районының  (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Кәче авыл җирлеге  башлыгы                    Р.Р.Гәрәев